# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы
Пыжмара авыл җирлеге составына керүче Пыжмара торак пункты

21 апрель 2023 ел № 12

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56нчы маддәләре, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында " 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35нче маддәсе нигезендә Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Пыжмар торак пунктында гражданнар җыены карар итте:

1. «2023 елда гражданнарның үзара салымын Балтач муниципаль районы Пыжмара авыл җирлегенең Пыжмара торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән 18 яшькә җиткән һәр кешедән 500 (Биш йөз) сум күләмендә кертергә (I төркем инвалидларга; үз-үзенә хезмәт күрсәтә алмаган гражданнарга; балигъ булмаган балалар тәрбияләүче ялгыз ата-аналарга (законлы вәкилләргә); Россия Армиясе сафларында ашыгыч һәм контракт хезмәте узучы хәрби хезмәткә чакырылучыларга, Россия Федерациясе кораллы көчләренә мобилизацияләнгән гражданнарга һәм аларның гаилә әгъзаларына 90% күләмендә ташлама каралган).

2. Алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә, түбәндәге эшләрне башкару өчен җибәрергә:

- Пыжмара авылының Г.Тукай, Яңа, С.Мөлеков урамнарын вак таш җәеп төзекләндерү;

- Пыжмара авылының Г. Тукай, Яңа, С.Мөлеков урамнарында су агымы торбалары урнаштыру.»

3. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының Пижмара авыл җирлегенең Пыжмара торак пункты гражданнар җыенының 20 октябрь 2022 елдагы 5 номерлы карары үз көчен югалткан дип танырга

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы Пыжмара авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының http://pravo.tatarstan.ru рәсми порталында, Балтач муниципаль районы сайтында http://baltasi.tatar.ru урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

5. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив актлары Регистрына кертү өчен җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче:
ТР Балтач муниципаль районы
Пыжмара авыл җирлеге башлыгы Р. Х. Заляев